**Р. К. Шәехова**



*Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы:*

# авазларны уйнатып

**Эш дәфтәре**
**2 нче кисәк**

Мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче балалар өчен

Казан
ХӘТЕР
2011

УДК 512.145
ББК 81.2Тат
Ш11

Рецензентлар:
**М. Г. Мозаффарова** —
*ТР Мәгарифне үстерү институтының мәгарифтә милли проблемалар лабораториясе мөдире, педагогика фәннәре кандидаты*
**Г. Х. Кәримова** —
*Казан шәһәре 50 нче балалар бакчасының югары квалификацион категорияле татар теленә өйрәтү тәрбиячесе*

Тышлык рәссамы ***Юлия Щетинкина***
Рәссамы ***Влада Семёнова***

**Шәехова, Р.К.**
Ш11 Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып : эш дәфтәре : 2 нче кисәк : мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче балалар өчен / М. С. Нургалиева тәрҗ.– Казан : Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011.– 72 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-94113-365-9

Бу ярдәмлек мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларны уку-язу нигезләрен үзләштерүгә әзерләү буенча шөгыльләр системасыннан гыйбарәт.
2 нче эш дәфтәрендәге уенлы биремнәр балаларда татар телендәге сузык авазларны хәрефләр белән билгеләү, сузык авазлар, калын һәм нечкә тартыкларны аеру, ишетелә торган сүзнең төзелеше белән кызыксыну сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән.
Эш дәфтәре мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларга, тәрбиячеләргә, ата-аналарга адресланә.

УДК 512.145
ББК 81.2Тат

ISBN 978-5-94113-365-9

© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011
© Шәехова Р. К., 2011

## Сәлам, дустым!

Тиздән, бик тиздән син укучы булырсың!

Укучы – зур максатларга бара торган кеше.

Беренче сыйныф укучылары калын-калын китаплар гына укыйлар, күп итеп язалар, беркайчан да уйнамыйлар, шаярмыйлар дип уйлый күрмә тагын. Бу һич тә алай түгел! Мәктәп тормышы бик кызыклы, мавыктыргыч ул! Син укытучылар ярдәмендә бик күп файдалы һәм кызыклы әйберләр белерсең. Ә үзең укырга өйрәнгәч, кояш һәм ай, хайваннар һәм кошлар, әкиятләрдәге яхшы һәм начар каһарманнар турында китаплардан укып белерсең.

Ә быел без синең белән тырышып мәктәпкә әзерләнербез. Мәктәптә яхшы укыр өчен, укырга һәм язарга өйрәнергә тырышырбыз. Син, сүзләр һәм авазлар белән уеннар уйнап, укуның кызыклы икәнен аңларсың. Тәрбияче апаларың сиңа һәрчак ярдәм итеп торыр.

Хәерле юл «Әлифба иле»нә, дустым!

Сиңа зур уңышлар телим!

*Автор*



Алмасы да алмасы –
Өзеп кенә аласы!
Өзмим әле – баллансын,
Бераз гына аллансын.
*Роберт Миңнуллин*

**1.** Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга. Балалар белән иллюстрация карыйлар, биргән сорауларга җавап бирәләр.

**2**. *Алма* һәм *Алсу* сүзләренә аваз анализы ясау.


**3**. *Алма* һәм *Алсу* сүзләренең модельләрен чагыштыру. Балалар тәрбияче белән бергәләп бу сүзләрдәге **[а]** авазларын табалар һәм модельдән бу авазларга туры килгән кызыл фишкаларны алып куялар.

«Ни өчен *Алсу* сүзендә бер кызыл фишка калды?» дигән сорау куела.

**4**. Тәрбияче **А, а** хәрефләрен күрсәтә, аларны балалар белән бергәләп карыйлар. Тәрбияче «кечкенә» яки юл хәрефе **а** турында сөйли, аның сүздә кайсы вакытта язылуын аңлата. Шулай ук «зур» яки баш **А** хәрефе турында сөйли, нинди сүзләрнең баш хәрефтән язылуын аңлата (кешеләрнең исем-фамилияләре, хайван кушаматлары, шәһәр, авыл, ил атамалары һ.б.).



**А а**





**5**. Тәрбияче **а** хәрефе язылган карточкалар өләшеп чыга. Балалар белән хәрефләр кассасын карыйлар, анда **а** хәрефенең урынын билгелиләр. Эш беткәч, хәрефләрне кассага үз урыннарына куярга кирәклеге аңлатыла. Бу турыда һәрвакыт балаларның исләренә төшереп торыла.


**6**. Балалар *алма* һәм *Алсу* сүзләренең модельләренә **А, а** хәрефләрен куялар. Тәрбияче такта янында эшләүче бала белән бергә ни өчен «зур» **А** яки «кечкенә» **а** хәрефләрен куюын аңлатып бирә.


Тәрбияче: «Хәзер **[а]** авазы урынына фишка түгел – **а** хәрефен куячакбыз», – дип тәмамлый.


**7. «Тере модельләр» уены** (*Алсу* сүзе белән).

1) фишкалар һәм хәреф авазларның сүздәге тәртибе буенча өләшенә;
2) балалар авазларның сүздәге урыннарын буташтырып чакырыла;
3) балалар фишкаларны һәм хәрефне үз урыннарына куялар;
4) балалар хәрефне кассаның тиешле кесәсенә урнаштыралар.








| | | |
|---|---|---|
| **а** | | |

| | | |
|---|---|---|
| | **а** | |

| | | |
|---|---|---|
| | | **а** |

**1**. Балалар басма **А** хәрефенең нәрсәгә охшаганын әйтәләр.


**2**. Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Аннан соң һәрбер сүздә **[а]** авазының урынын билгелиләр (сүз башында, сүзнең уртасында, сүз ахырында). Һәр рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыралар.

*Алма, бака, арба* сүзләренә игътибар итеlә – алар икешәр схема белән тоташтырылган булырга тиешләр.

**3.** Балалар рәсемдәге предметларны төркемнәргә бүләләр һәм үзләренең җавапларын дәлилләп бирәләр.







**4**. **«Минем исемем ничек?» уены.**

Тәрбияче фишкаларны бүлмәнең төрле җиренә куя, мәсәлән, тәрәзә төбенә кызыл фишка, тактага — зәңгәр, ишеккә — яшел. Эш барышында бу фишкаларның нинди авазларны белдерүләре ачыклана. Балаларга үз исемнәрен әйтергә һәм аның беренче авазын билгеләргә тәкъдим ителә. Бу авазның нинди аваз булуы ачыклана (сузык, калын әйтелә торган тартык, нечкә әйтелә торган тартык).

Тәрбияче сигналы буенча, балалар үз фишкалары янына барып басалар. Бирем үтәлешенең дөреслеген балалар үзләре тикшерәләр. Тәрбияче күзәтеп кенә тора.

**5**. Балалар **А, а** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар. Язу барышында кул хәрәкәтенең башлангычын күрсәтүче нокталарга, хәрәкәтнең юнәлешен күрсәтүче укларга игътибар итәргә кушыла. Язу хәрәкәтенең нокталар һәм уклар күрсәткәнчә үтәлергә тиешлеге аңлатыла.

**Сүзләр белән эш:**

I схема: *алма, арба, ат;*

II схема: *шар, балык, шалкан, маймыл, бака, курчак;*

III схема: *бака, алма, арба.*



Әминә елый үкереп,
Тубым суга төште, дип.
– Чү, Әминә, елама,
Туп батмый ул елгада.

*Әминә Бикчәнтәева*

**1.** Тәрбияче Ә. Бикчәнтәеванын «Туп» шигырен укып чыга. Балалар белән бергәләп иллюстрация карыйлар. Тәрбияче шигырьне сөйләргә теләгән балаларны үз янына чакыра.

**2.** *Мәк* һәм *Әминә* сүзләренә аваз анализы ясау.

**3.** Балалар *мәк* һәм *Әминә* сүзләрендә бертөрле сузык авазларны табалар. Бу авазларга туры килгән фишкаларны сүзнең моделеннән алып куялар.


Тәрбияче **Ә, ә** хәрефләрен күрсәтә, аларны балалар белән бергәләп карыйлар, нәрсәгә охшаганын әйтәләр. Аннан соң тәрбияче **[ә]** авазын язуда белдерүче **ә** хәрефенең татар телендә генә кулланылуына балаларның игътибарын юнәлтә. «Кечкенә» яки юл хәрефе **ә** турында сөйли, аның сүздә кайсы вакытта язылуын аңлата. Шулай ук «зур» яки баш **Ә** хәрефе турында сөйли, нинди сүзләрнең баш хәрефтән язылуын балаларның исләренә төшерә.

Тәрбияче балаларга **ә** хәрефе язылган карточкалар өләшеп чыга, хәрефләр кассасында аның урынын билгелиләр.



# Әә





**4.** Балалар *мәк* һәм *Әминә* сүзләренең модельләренә **Ә, ә** хәрефләрен куялар. Тәрбияче белән бергәләп такта янында эшләүче бала ни өчен «зур» **Ә** һәм «кечкенә» **ә** хәрефләрен куюын аңлатып бирә.

Тәрбияче: «Хәзер **[ә]** авазы урынына фишка түгел, **Ә, ә** хәрефләрен куячакбыз», – дип белдерә.

**5.** **«Тере модельләр» уены** (*Әминә* сүзе белән).

**Сүзләр белән эш:** *мәк, Әминә.*



**Әтәч**

Иң матур төш күргәндә,
Төшкә әни кергәндә,
Тотына кычкырырга –
Туры килә торырга.
«Тор-тор!» – диеп әйткәч тә,
Үпкәләмим әтәчкә!

*Роберт Миңнуллин*

**1**. Тәрбияче: «Гаиләгездә иң кадерле кешеләр кемнәр алар?» – дип балаларга сорау бирә. Алар турында сөйләп бирергә куша.

**2**. Тәрбияче Р. Миңнуллинның «Әтәч» шигырен укый, балалар белән бергәләп иллюстрация карыйлар, сорауларга җавап бирәләр.

**3.** Тәрбиячнең кыскача мәгълүмат бирүе: «Сез беләсезме? Әтәч – ул ...».






| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ә | | | ә | | | | ә |


**4**. Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Рәсемдәге предметларны төркемнәргә бүләләр һәм үзләренең җавапларын дәлилләп бирәләр. Аннан соң һәрбер сүздә **[ә]** авазының урынын билгелиләр: сүз башында, уртасында, ахырында.

Һәр рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыралар.

*Әтәч, кәҗә* сүзләренә игътибар итеплә – алар икешәр схема белән тоташтырылган булырга тиешләр.

## 46 нчы шөгыль







**5**. Балалар **Ә, ә** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар. Язу барышында кул хәрәкәтенең башлангычын күрсәтүче нокталарга, хәрәкәтнең юнәлешен күрсәтүче укларга игътибар итү күнекмәсе формалаштырыла.

**Сүзләр белән эш:** *гаилә, әби, әти, әни;*
I схема: *әфлисун, әлифба, әтәч;*
II схема: *мәк, имән, күбәләк, әтәч, кәҗә;*
III схема: *энә, төймә, кәҗә.*



## 47 нче шөгыль





**1. «Бер һәм күп»** (туп белән уен).
Тәрбияче, сүзне берлек санда әйтеп, балага тупны ыргыта. Бала, шул ук сүзне күплек санда әйтеп, тупны кире кайтара.
**2. Мөстәкыйль эш.**
*Туп* сүзенә аваз анализы ясау. Биремне тизрәк үтәп бетергән бала такта янында эшли, бергәләп дөреслеген тикшерәләр.
*Туп* сүзенең моделен *туплар* сүзе моделенә үзгәртү. Биремне яхшырак үзләштергән бала такта янына чакырыла.
*Туплар* сүзенә аваз анализы ясау. «Сүздә ничә сузык аваз бар?», «Ничә тартык аваз?», «Нечкә тартыклар бармы?» кебек сораулар куела.

# Уу



Тук-тук тукран,
Тукылдатып утырам.
Мичтә бәлеш пешәме?
Шуны көтеп утырам.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**3.** Тәрбияче тел көрмәкләндергечне укый, үзе артыннан кабатларга куша. Аннан соң йодрыкка йомарланган бармакларның ритмик хәрәкәтләре ярдәмендә кабатлау эше дәвам иттерелә.

**4. Мөстәкыйль эш.**

*Тукран* сүзенә аваз анализы ясау. Биремне яхшырак үзләштергән бала такта янына чакырыла.

**5.** Тәрбияче балаларга *туплар* һәм *тукран* сүзләрендә бертөрле авазларны табарга һәм кызыл фишка урынына **а** хәрефен куярга тәкъдим итә.

**6. У, у** хәрефләре белән таныштыру. Балаларга кайсы очракта «зур» (баш) хәреф, кайсы очракта «кечкенә» (юл) хәреф язылуы аңлатып бирелә.

Тәрбияче балаларга **у** хәрефе язылган карточкалар өләшеп чыга. Алар **у** хәрефен сүзләрнең модельләренә куялар. Кассада бу хәрефнең урынын билгелиләр һәм шунда урнаштырып куялар.

**Сүзләр белән эш:** *туп, туплар, тукран.*





| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| у | | | у | | | | у |


**1.** Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Аннан соң эзлекле рәвештә һәрбер сүздә **у** хәрефе белән билгеләнгән **[у]** авазының урынын билгелиләр. Һәр рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыралар.


**2.** Тәрбияченең кыскача мәгълүмат бирүе: «Сез беләсезме? Умарта – ул ...».

**3. «Тере модельләр» уены (*умарта* сүзе белән).**

1) фишкалар һәм хәрефләр авазларның сүздәге тәртибе буенча өләшенә;
2) балалар авазларның сүздәге тәртибен буташтырып чакырыла: **[у]** авазы, беренче **[а]** авазы, **[т]** авазы, **[м]** авазы, **[р]** авазы, соңгы **[а]** авазы;
3) балалар фишкаларны һәм хәрефләрне үз урыннарына куялар: беренче сузык аваз, икенче сузык аваз, өченче сузык һәм калын тартык авазларны урыннарына куялар.

## 48 нче шөгыль





4. Балалар **У, у** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**5. «Парын тап»** (туп белән уен).

Тәрбияче, калын әйтелешле тартык аваздан башланган сүз әйтеп, тупны балага ыргыта. Бала, калын әйтелешле тартыкның нечкә әйтелешле парыннан башланган сүз әйтеп, тупны кире кайтара (*кузгалак – күз, такта – тән, ...*).


**Сүзләр белән эш:**

I схема: *умарта, урындык, умырзая, укучы;*
II схема: *тукран, суган, курчак, укучы;*
III схема: *дару, бозау.*




## 49 нчы шөгыль










**1. Мөстәкыйль эш.**


*Кул* һәм *күл* сүзләренә аваз анализы ясау.


**2.** Балаларга *кул* һәм *күл* сүзләренең охшашлыгына игътибар итәргә кушыла (*кул* сүзендә беренче аваз – калын әйтелешле тартык аваз, *күл* сүзендә беренче аваз – нечкә әйтелешле тартык аваз). Ике сүзнең дә икенче авазлары – сузык авазлар. Калын әйтелешле тартыктан соң аны **у** хәрефе белән билгелиләр. Нечкә әйтелешле тартыктан соң **[у]** авазы ишетелсә дә – **у** хәрефе язылмый. **[у]** авазы нечкә әйтелешле тартыктан соң **ү** хәрефе белән билгеләнә.

## 49 нчы шөгыль

# Үү








**3**. Тәрбияче **Ү, ү** хәрефләре (баш һәм юл) белән таныштыра. «**Ү** хәрефе нәрсәгә охшаган?» – дип сорау бирә. Аннан соң тәрбияче **[ү]** авазын язуда белдерүче **ү** хәрефенең татар телендә генә кулланылуына балаларның игътибарын юнәлтә.

Хәрефнең язылу кагыйдәсен балалар белән бергәләп формалаштыралар. Хәрефләр кассасы белән эш, алдагы хәрефләр белән таныштыргандагы кебек үк алып барыла.


**4**. *Сүз* сүзенә аваз анализы ясау.


*Сүз* сүзенең моделен *сүзлек* сүзе моделенә үзгәртү.

**5**. Тәрбияченең кыскача мәгълүмат бирүе: «Сез беләсезме? Сүзлекләр – ул ...».



## 49 нчы шөгыль





**6**. Балалар **Ү, ү** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар, аларның язылышындагы охшашлыкны һәм аерманы табып әйтәләр.

**Сүзләр белән эш:** *күл, кул, сүз, сүзлек.*

у ? ү














1. Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Башта ук белән күрсәтелгән шакмакларны **у** яки **ү** хәрефләре белән билгелиләр. Аннан соң тиешле хәрефне кызыл карандаш белән язалар. Балалар сүзләрдәге тартык авазларның калын яки нечкә әйтелешле булуын әйтеп бирергә тиешләр. Мисал өчен бер сүз тактада тикшерелә. Аннан соң балалар мөстәкыйль эшлиләр.

2. **Кроссворд чишү**. Кроссворд тактада сызыла, ләкин рәсемнәрне тактада ясау кирәк түгел. Урыннарда балалар һәрбер уйлап табылган сүзне аңа туры килгән рәсем белән тоташтыралар.











у
ү
у
ү
ү
ү











**3. «Игътибарлы бул!» уены.**

Тактада аслы-өсле яшел һәм зәңгәр фишкалар. Тәрбияче, балалар әйтүе буенча, зәңгәр фишка артына – **а, у** хәрефләрен; яшел фишка артына **ә, ү** хәрефләрен куя.

**4. «Көн-төн» уены**.

Тәрбияче *төн* сүзен әйткәч, балалар күзләрен йомалар, шул вакытта ул **а** һәм **ә** хәрефләренең урыннарын алмаштырып куя. Тәрбияче «көн» дигәч, балалар күзләрен ачалар һәм нәрсә үзгәрүен әйтеп бирергә тиеш булалар. **У** һәм **ү** хәрефләре белән дә шундый ук эш башкарыла.

**5. «Соңгы авазны үзгәртеп, яңа сүз китереп чыгар»** биреме *(кул-кук, күз-күп, бал – ..., кар – ..., тау – ...).*

**6.** Тәрбияче: «Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә» әйтемен сез ничек аңлыйсыз?» – дип балаларга сорау бирә. Ничек аңлауларын сөйләп бирергә куша.

**Сүзләр белән эш:** *гармун, күлмәк, бозау, укучы, үтүк, үлчәү;*
*курчак, кәтүк, автобус, Шүрәле, күбәләк, күркә.*



Чигү чигә чибәрләр,
Чибәр чигү чигәләр.
Әни белән Иркә чигү чигә,
Алар чирәм чигәләр.

**1.** Тәрбияче тизәйткечне укый, кайсы сузык авазның еш очравын сорый. (**[и]**). Балаларга «Кемнәр чигү чигәләр?» соравы куела.

Тактада, дәфтәрдәге кебек үк, *әни, Иркә* сүзләренең схемалары ясалган. Балаларга кайсы схеманың беренче, кайсының икенче сүзгә туры килүен ачыкларга кушыла. Такта янында эшләүче бала, тәрбияче белән бергәләп, схемалар буенча сүзләрне «укый».

**2.** Тәрбияче балаларны **И, и** хәрефләре (баш һәм юл) белән таныштыра, **и** хәрефе язылган карточкалар өләшеп чыга. Балалар *әни* һәм *Иркә* сүзләренә **И, и** хәрефләрен куялар. Тәрбияче белән бергәләп, такта янында эшләүче бала ни өчен «зур» **И** яки «кечкенә» **и** хәрефләрен куюын аңлатып бирә. Тәрбияче: «Хәзер **[и]** авазы урынына фишка түгел, **и** хәрефен куячакбыз», – дип нәтиҗә ясый.



51 нче шөгыль

# Ии



**3. «Тере модельләр» уены** (*Иркә* сүзе белән).

**4.** Балалар *дәү әни* сүзтезмәсендә сузык авазларны табалар. Сүзтезмәнең моделендә бу авазларга туры килгән фишкаларны **ә, ү, и** хәрефләренә алмаштыралар.

**5. «Синең исемеңдә [и] авазы бармы?» уены.**


Бу уенны оештыруга тәрбияче иҗади якын килергә мөмкин. Мәсәлән:

– исемендә **[и]** авазы булган малайлар, – басыгыз;
– исемендә **[и]** авазы булган кызлар, – басыгыз;
– исемендә **[и]** авазы уртада булган малайлар һәм кызлар, – басыгыз һ.б.

**6. «Сүзләр чылбыры» уены.**

Балалар ике рәткә тезелеп басалар. Беренчеләргә тәрбияче бер сүз әйтә. Бала бу сүзнең соңгы авазын аерып, шул ук авазлан башланган икенче сүз әйтә. Уен шулай дәвам итә. Кайсы рәттә соңгы бала алданрак сүз уйлап әйтсә, шул команда җиңүче була. Тәрбияче, рәтләр арасында торып, сүзләрнең дөреслеген тикшерә.


**Сүзләр белән эш:** *әни, Иркә, дәү әни.*










| | | |
|---|---|---|
| и | | |

| | | |
|---|---|---|
| | и | |

| | | |
|---|---|---|
| | | и |

**1. Мөстәкыйль эш.**

Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Һәр рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыралар. Бу эш тактада башкарылмый.

**2.** Балалар рәсемдәге предметларны төркемнәргә бүләләр һәм үзләренең җавапларын дәлилләп бирәләр.


**3. «Үз өеңне тап» уены.**

Яхшырак әзерлекле ике бала – уенны алып баручылар. Берсенең кулында зәңгәр фишка, икенчесендә – яшел фишка. Калган балаларның кулында берәр сузык аваз хәрефе. «Хәрефләр» бүлмә буйлап йөриләр. Тәрбияче сигналы буенча алар үз өйләре янына барып басарга тиешләр. Бу очракта «өй» – тиешле фишка тоткан алып баручы бала. Алып баручы балалар «хәрефләрнең» дөрес басу-басмауларын тикшерәләр.





| | | |
|---|---|---|
| | и | |






| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | и | | ә | |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | у | | а | |



| | | | |
|---|---|---|---|
| ү | | ә | |






| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| ә | | и | | | а |


| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | у | | | а | | а | |

**4. «Модель буенча сүзне уйлап әйт» уен-биреме.**

Рәсемнәргә туры килгән сүзләрне атау. Аларның модельләрен табу һәм аларны рәсем белән тоташтыру.

## 52 нче шөгыль




**5.** Балалар **И, и** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**Сүзләр белән эш:** *фил, җиләк, суган, әлифба, үлән, тузганак;*
I схема: *ипи, иләк;*
II схема: *чия, кишер, чиләк, читек;*
III схема: *әби, песи, ипи, чеби.*



## 53 нче шөгыль




Ылыс исе бөркеп тора,
Урманда чыршы, нарат.
Шул агачларга карагач,
Шатланам кабат-кабат.

**1.** Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга. Балаларга **[ы]** авазы кергән сүзләрне аерып алырга куша.
**2.** *Ылыс* һәм *чыршы* сүзләренә аваз анализы ясау.
**3.** Балалар *ылыс* һәм *чыршы* сүзләрендә бертөрле авазларны табалар. Бу авазларга туры килгән кызыл фишкаларны модельләрдән алып куялар.
**4.** Тәрбияче балаларны **Ы, ы** хәрефләре (баш һәм юл) белән таныштыра, (Р. Миңнуллинның «Ыргак» шигырен искә төшереп үтәргә мөмкин).
Тәрбияче балаларга **ы** хәрефе язылган карточкалар өләшеп чыга. Балалар хәрефне модельләргә куялар. Эш беткәч, карточкаларны хәрефләр кассасына алып куялар.

# Ыы







5. **«Модель буенча сүзне уйлап әйт» уены.** Тактада 4 аваздан торган сүз моделе. Балалар шул модель буенча сүзләр әйтеп бирәләр (*бала, дару, тары, солы ...*). Күбрәк фишка җыйган бала җиңүче итеп таныла.

6. **«Рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыр» уен-биреме.**

Балалар барлык рәсемнәрне атап чыгалар. Һәр рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыралар.
























| ы | |
|---|---|

| | ы | |
|---|---|---|

| | ы |
|---|---|


**Сүзләр белән эш:** *чыршы, ылыс;*


I схема: *ыргак;*

II схема: *сыр, башлык, тычкан, балыкчы, кыш, сабын, мылтык;*

III схема: *балыкчы, кайчы.*

## 54 нче шөгыль





**1**. Балалар **Ы, ы** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**2. «Игътибарлы бул» уены.**


Тактада һәм балаларның өстәлләрендә аслы-өсле яшел һәм зәңгәр фишкалар. Балалар **а-ә, у-ү, и, ы** хәрефләрен тиешле фишкалар артына куярга тиешләр.

**3. «Көн-төн» уены**.

Тәрбияче *төн* сүзен әйткәч, балалар күзләрен йомалар, шул вакытта ул **а** һәм **ә** хәрефләренең урыннарын алмаштырып куя. Тәрбияче «көн» дигәч, балалар күзләрен ачалар һәм нәрсә үзгәрүен әйтеп бирергә тиеш булалар. **У-ү, и, ы** хәрефләре белән дә шундый ук эш башкарыла.



## 54 нче шөгыль



**4.** Балалар кызыл карандаш ярдәмендә ук белән күрсәтелгән шакмакларга тиешле хәрефләрне язып куялар.

**5. «Сүзләр чылбыры» уены.**

Балалар ике рәткә тезелеп басалар. Беренчеләргә тәрбияче бер сүз әйтә. Бала бу сүзнең соңгы авазын аерып, шул ук аваздан башланган икенче сүз әйтә. Уен шулай дәвам итә. Кайсы рәттә соңгы бала алданрак сүз уйлап әйтсә, шул команда җиңүче була. Тәрбияче, рәтләр арасында торып, сүзләрнең дөреслеген тикшерә.

**Сүзләр белән эш:** *сарык, тычкан, дуңгыз, тавык.*

Элгеч биек, шуңадырмы
Өзелгән бит элмәгем.
Тегәргә дип тотындым,
Энә саплый белмәдем.



**1.** Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга. Балаларга **[э]** авазы кергән сүзләрне аерып алырга куша.

**2.** *Энә* һәм *элмәк* сүзләренә аваз анализы ясау.

**3**. Балалар *энә* һәм *элмәк* сүзләрендә бертөрле авазларны табалар, бу авазларга туры килгән кызыл фишкаларны модельләрдән алып куялар.

Тәрбияче балаларны **Э, э** хәрефләре (баш һәм юл) белән таныштыра. «Рус теленнән кергән сүзләрдә бу хәреф сүз башында, уртасында һәм ахырында язылa (*экран, аэропорт, алоэ*). Ә татар телендә **[э]** авазы сүзнең башында, уртасында һәм ахырында ишетелсә дә, бу авазны белдергән **э** хәрефе һәрвакыт сүз башында гына языла», – дип белдерә.



# Ээ





**4. «Тере модельләр» уены** *(элмәк* сүзе белән*).*

**5. «Үз өеңне тап» уены.**

Яхшырак әзерлекле ике бала – уенны алып баручылар. Берсенең кулында зәңгәр фишка, икенчесендә – яшел фишка. Калган балаларның кулында берәр сузык аваз хәрефе. «Хәрефләр» бүлмә буйлап йөриләр. Тәрбияче сигналы буенча, алар үз өйләре янына барып басарга тиешләр. Бу очракта «өй» – тиешле фишка тоткан алып баручы бала. Алып баручы балалар «хәрефләрнең» дөрес басу-басмауларын тикшерәләр.

**Сүзләр белән эш:** *энә, элмәк.*




**Эт миңа тел күрсәтә**


Үчекләме мине эт,
Әллә: «Эссе!» – диме эт?
Күрсәтә миңа телен,
Аңлый алмыйм тел төбен.
Ә-ә, ул салкын сагынган!
Теле шуңа салынган.

*Роберт Миңнуллин*

1. Тәрбияче Р. Миңнуллинның «Эт миңа тел күрсәтә» дигән шигырен укый. Рәсем буенча балалар белән әңгәмә үткәрә.







**2.** Тәрбияченең кыскача мәгълүмат бирүе: «Сез беләсезме? Эт – ул...».

**3.** *Эт* һәм *эссе* сүзләренә аваз анализы ясау.

Тәрбияче *эссе* сүзенең әйтелешенә игътибар итәргә куша: «Бу сүздә **[с]** авазы озын итеп әйтелә. Ул ике **с** хәрефе белән билгеләнә».

**4.** Балалар **Э, э** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

## 56 нчы шөгыль






| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| э | | | | |
| э | | ә | | |
| э | | а | | |
| э | | | а | |







**5. «Модель буенча сүзне уйлап әйт» уен-биреме.**
Балалар рәсемнәргә туры килгән сүзләрне атыйлар. Аларның модельләрен табалар һәм рәсем белән тоташтыралар.

**6. «Нәрсә артыннан нәрсә килә?» уен-биреме.**
Уен ярыш кебек үткәрелә. Балалар зәңгәр һәм яшел фишкалар артыннан сузык авазларның хәрефләрен куеп өлгерергә тиешләр. Тәрбияче бу эшнең яңа ысулын күрсәтеп китәргә мөмкин: хәрефләрне аслы-өсле итеп парлап куярга була (**а-ә, у-ү, и, ы-э**).

**Сүзләр белән эш:** *эт, эссе, энә, этаж, экран.*



## 57 нче шөгыль

# О о



Орчык әйләнә зырылдап,
Оркыя эрли җырлап.

**1.** Тәрбияче шигъри юлларны укый. Балаларга **[о]** авазы кергән сүзләрне аерып алырга куша. Бергәләп *орчык* сүзенә аваз анализы ясыйлар.

**2. Мөстәкыйль эш.**
*Тоз* сүзенә аваз анализы ясау.

**3.** Балалар *тоз* һәм *орчык* сүзләрендә бертөрле сузык авазларны табалар. Тәрбияче балаларга **О, о** хәрефләрен күрсәтә. Сүзләр моделендә бу авазларга туры килгән фишкаларны **о** хәрефенә алыштыралар.








Рәсемдәге кызның исеме – Оркыя. Алга таба балаларга түбәндәге сораулар куела:

– Аның исеме нинди хәрефтән башлана?

– Сез ничек уйлыйсыз, бу хәреф – баш хәрефме? Әллә юл хәрефме? Ни өчен?

**4.** *Орчык* һәм *борчак* сүзләренә чагыштырма анализ.

Балалар бу сүзләрдәге бертөрле авазларны әйтеп бирәләр (**о, р, ч, к**).

*Орчык* һәм *борчак* сүзләренең модельләренә таныш хәрефләрне куялар: **о, а, ы**.






















| | |
|---|---|
| о | |

| | | |
|---|---|---|
| | о | |

| | |
|---|---|
| | о |

**5.** Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Аннан соң һәрбер сүздә **о** хәрефенең урынын билгелиләр (сүзнең башында, уртасында, ахырында). Һәр рәсемне аңа туры килгән схема белән тоташтыралар. Тәрбияче *Буратино, вагон, радио* сүзләренә игътибар юнәлтә.

## 57 нче шөгыль



6. Балалар **О, о** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**Сүзләр белән эш:** *Оркыя, орчык, тоз, борчак;*
I схема: *оекбаш, оя;*
II схема: *борчак, ботак, торна, кояш, вагон;*
III схема: *Буратино, радио.*



## 58 нче шөгыль



**1.** Тәрбияче «Төлке белән Торна» әкиятенең эчтәлеген искә төшерә. Балалар белән бергәләп иллюстрация карыйлар. Аларга әкиятнең ахырын уйлап чыгарырга тәкъдим итә. Әкиятне сөйләргә теләгән балаларны үз янына чакыра.
**2. «Тере модельләр» уены (***төлке* сүзе белән).




# Өө




3. **«Киресен әйт» уены** *(кыска – озын, тиз – озак, яшь – олы, каршылау – озату, көн – төн ...).*
4. *Көн, төн* сүзләренә чагыштырма аваз анализы ясау.









**5.** Тәрбияче балаларга **Ө, ө** хәрефләрен күрсәтә һәм өләшеп чыга. «Бу хәреф нинди хәрефкә охшаган?» дигән сорау куела, аның татар теленә генә хас булуы искәртеп үтелә. Хәрефләр кассасы белән эш алдагы хәрефләр белән таныштыргандагы кебек алып барыла.

**6.** Балалар **Ө, ө** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**Сүзләр белән эш:** *төлке, көн, төн.*





| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ө | | | | | | |
| | а | | а | | | | |
| | о | | | а | | | |
| ө | | | ә | | | | |
| | ө | | | ә | | ә | |







**1. Кроссворд чишү.**

Кроссворд тактада сызыла. Тәрбияче, балалар белән бергәләп, һәрбер сүзгә аңлатма биреп, аны тиешле схема буенча «укый».

**2. «Парын тап»** (туп белән уен).

Тәрбияче калын әйтелешле тартык аваздан башланган сүз әйтеп, тупны балага ыргыта, бала шулай ук нинди дә булса калын әйтелешле тартык аваздан башланган сүз әйтеп, тупны кире кайтара. Аннан соң шул ук тәртиптә нечкә әйтелешле тартык аваздан башланган сүзләр белән уен дәвам иттерелә.

**3. «Игътибарлы бул!» уены.**

Һәр бала алдында аслы-өсле яшел һәм зәңгәр фишкалар. Балалар мөстәкыйль рәвештә яшел фишка артына – нечкә әйтелешле тартык аваз артыннан языла торган сузык авазларны **[ә, ү, и, э, ө]**; ә зәңгәр фишка артына калын әйтелешле тартык аваз артыннан языла торган сузык авазларны **[а, у, ы, о]** куярга тиешләр.

Бер бала бу биремне такта янында башкара. Фишкалар артында баш хәреф түгел, ә юл хәреф торырга тиешлек искәртелә. Биремнең дөреслеге такта янында тикшерелә.

**4. «Көн-төн» уены.**

Тәрбияче *төн* сүзен әйткәч, балалар күзләрен йомалар, бу вакытта **а-ә** хәрефләренең урыннары алыштырып куела, тәрбияче «көн» дигәч, балалар күзләрен ачалар һәм нәрсә үзгәрүен әйтәләр. **У-ү, ы-э, о-ө** хәрефләре белән дә шундый ук эш башкарыла.

**Сүзләр белән эш:** *сөт, балан, торна, өстәл, гөмбә.*





| а | ? | ә |
|---|---|---|











**5.** а) балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар һәм һәр сүздә нинди хәреф **(а-ә)** язарга кирәклеген билгелиләр. Аннан соң тиешле хәрефне ук белән күрсәтелгән шакмакка кызыл карандаш белән язып куялар.

**Сүзләр белән эш:** *ләлә, имән, чалбар, әлифба, карга.*

**у** **?** **ү**











б) балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар һәм һәр сүздә нинди хәреф (**у-ү**) язарга кирәклеген билгелиләр. Аннан соң тиешле хәрефне ук белән күрсәтелгән шакмакка кызыл карандаш белән язып куялар.

**Сүзләр белән эш:** *умарта, күркә, үрдәк, уенчыклар, күз.*






**ы** **?** **э**












**в)** балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар һәм һәр сүздә нинди хәреф (**ы-э**) язарга кирәклеген билгелиләр. Аннан соң тиешле хәрефне ук белән күрсәтелгән шакмакка кызыл карандаш белән язып куялар.

**Сүзләр белән эш:** *эт, эскимо, аэропорт, чыбыркы, тырнак.*

## 59 нчы шөгыль




г) балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар һәм һәр сүздә нинди хәреф (о-ө) язарга кирәклеген билгелиләр. Аннан соң тиешле хәрефне ук белән күрсәтелгән шакмакка кызыл карандаш белән язып куялар.

**Сүзләр белән эш:** *өй, он, кояш, көрәк, нота.*



## 60 нчы шөгыль



Яшел, ләкин яфрак түгел,
Озынча, ләкин ташкабак түгел,
Түтәлдә үсә, ләкин суган түгел.


**1**. Тәрбияче балаларга табышмак әйтә һәм түбәндәге сорауны бирә: «Ясминә нәрсә җыя?» *(Кыяр)*. Балаларга рәсем буенча табышмаклар төзергә куша.


**2**. Тәрбияче, балалар белән бергәләп, *Ясминә* сүзенә аваз анализы ясый.

Интонация ярдәмендә сүзнең беренче **[й]** авазын аерып алып әйтегез һәм аңа туры килгән яшел фишканы куегыз. Тавышны көчәйтебрәк икенче **[ә]** авазын әйтегез һәм аңа туры килгән кызыл фишка белән билгеләгез. Өченче **[с]** авазын әйтегез һәм яшел фишканы куегыз. Дүртенче **[м]** авазын әйтегез һәм яшел фишка белән билгеләгез. Аның артыннан **[и]** авазын әйтегез һәм кызыл фишканы куегыз. **[н]** авазына туры килгән яшел фишканы, **[ә]** авазына – кызыл фишканы куегыз. Сүзгә анализ ясап бетергәннән соң, тәрбияче түбәндәге кагыйдәне әйтә: **«Әгәр дә сүздә [й] һәм [ә] авазлары бер-бер артлы торсалар** *(модельдә аларга туры килгән фишкалар күрсәтелә)*, **аларны бер хәреф – Я хәрефе белән билгелиләр. Бу очракта авазлар нечкә итеп әйтелә.** Игътибарлы булыгыз, авазлар – ике, ә хәреф – бер. Фишкалар өстенә **я** хәрефе язылган карточка куела. Аннан соң бергәләп сүздәге авазларны (фишкаларны) санайлар һәм беренче ике фишканы алып куялар, алар урынына **я** хәрефе куела.


# Я я







я



я

Рәсемдәге кызның исеме – Ясминә. «Аның исеме нинди хәрефтән башлана?», «Бу хәреф баш хәрефме, әллә юл хәрефме? Ни өчен?» – дигән сораулар бирелә.


**3.** *Кыяр* сүзенә аваз анализы ясау.


Интонация ярдәмендә беренче **[к]** авазын аерып алып, сүзне әйтеп бирегез. Аңа туры килгән зәңгәр фишканы куегыз. Икенче **[ы]** авазын аерып әйтегез һәм кызыл фишка куегыз. Өченче **[й]** авазын аерып әйтегез, аңа туры килгән зәңгәр фишканы куегыз. Аның артыннан **[а]** авазын әйтегез һәм кызыл фишканы куегыз. **[р]** авазын зәңгәр фишка белән билгеләгез.

Авазлар белән эшне тәмамлаганнан соң, тәрбияче түбәндәге кагыйдәне әйтә: **«Әгәр дә сүздә [й] һәм [а] авазлары бер-бер артлы торсалар, аларны Я хәрефе белән билгелиләр. Бу очракта авазлар калын итеп әйтелә.**

Балалар сүздәге авазларны (фишкаларны) санийлар һәм өченче, дүртенче фишкаларны алып, алар урынына **я** хәрефе куялар.







**4. «Тере модельләр» уены** *(кыяр* сүзе белән).

**5.** Балалар **Я, я** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**Сүзләр белән эш:** *кыяр, Ясминә.*



Аю килгән Казанга,
Кереп чыккан базарга.
Килгән аю бал өчен –
Сизгән юкә балы исен.
Тик юлы уңмаган, ди –
Акчасы булмаган, ди.

**1.** Тәрбияче шигъри юлларны укып чыга. Балаларның игътибарын *аю, юл, юкә* сүзләренә юнәлтә.


**2.** *Юл* сүзенә аваз анализы ясау. Интонация ярдәмендә беренче **[й]** авазын аерып алып әйтегез һәм аңа туры килгән зәңгәр фишканы куегыз. Тавышны көчәйтебрәк икенче **[у]** авазын әйтегез һәм аңа туры килгән кызыл фишканы куегыз. Өченче **[л]** авазын әйтегез һәм зәңгәр фишканы куегыз.

Сүзгә анализ ясап бетергәннән соң, тәрбияче түбәндәге кагыйдәне әйтә: **«Әгәр дә сүздә [й] һәм [у] авазлары бер-бер артлы торсалар** *(модельдә аларга туры килгән фишкалар күрсәтелә)*, **аларны бер хәреф – Ю хәрефе белән билгелиләр. Бу очракта авазлар калын итеп әйтелә.** Игътибарлы булыгыз, авазлар – ике, ә хәреф – бер. Фишкалар өстенә **ю** хәрефе язылган карточка куела. Аннан соң бергәләп сүздәге авазларны (фишкаларны) санайлар һәм беренче ике фишканы алып куялар, алар урынына **ю** хәрефе куела.




# Юю








**3.** *Юкә* сүзенә аваз анализы.

– Бу сүздә ничә сузык аваз бар?

– Нинди авазлар? ([ү], [ә].)

– Ничә тартык аваз? Калын әйтелешлеме яки нечкә әйтелешлеме? ([й], [к] – нечкә әйтелешле тартык авазлар).


**4. «Тере модельләр» уены** (*юкә* сүзе белән).


1) фишкалар сүздәге авазларның тәртибе буенча өләшенә: [й], [ү], [к], [ә];

2) балалар сузык авазлар, тартык авазлар буенча чакырыла;

3) балалар схемага **ю** хәрефен куялар. ([й], [ү] авазларын белдерүче балалар бергәләп чыга, фишкаларны хәрефкә алмаштыралар.) Аннан соң схемага **ә** хәрефе, [к] авазын белдерүче фишка куела.

## 61 нче шөгыль





**5.** Балалар **Ю, ю** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

**6. «Үз өеңне тап» уены.**

Яхшырак әзерлекле ике бала – уенны алып баручылар. Берсенең кулында зәңгәр фишка, икенчесендә – яшел фишка. Калган балаларның кулында берәр сузык аваз хәрефе. «Хәрефләр» бүлмә буйлап йөриләр. Тәрбияче сигналы буенча алар үз өйләре янына барып басарга тиешләр. Бу очракта «өй» – тиешле фишка тоткан алып баручы бала. Алып баручы балалар «хәрефләр»нең дөрес басу-басмауларын тикшерәләр.

**Сүзләр белән эш:** *юл, юкә.*



## 62 нче шөгыль



Күпме карасам да, карап туймыйм
Идел буе каеннарына.
Алар житәкләшеп яланаяк
Чыгар төсле Идел ярына.

*Әхмәт Ерикәй*

**1.** Тәрбияче балаларга түбәндәге сорауларны бирә:
– Әйтегез әле, нәрсә ул Идел? (*Елга.*)
– Сез Идел турында нәрсәләр беләсез? Сөйләп бирегез.

**2.** *Елга* сүзенә аваз анализы ясау.

Интонация ярдәмендә сүзнең беренче **[й]** авазын аерып алып әйтегез һәм аңа туры килгән фишканы куегыз. Тавышны көчәйтебрәк икенче **[ы]** авазын әйтегез һәм аңа туры килгән кызыл фишканы куегыз. Өченче **[л]** авазына туры килгән зәңгәр фишканы куегыз. Дүртенче **[г]** авазына туры килгән зәңгәр фишканы куегыз. Бишенче **[а]** авазына туры килгән кызыл фишканы куегыз.

Сүзгә анализ ясап бетергәннән соң, тәрбияче түбәндәге кагыйдәне әйтә: **«Әгәр дә сүздә [й] һәм [ы] авазлары бер-бер артлы торсалар** (модельдә аларга туры килгән фишкалар күрсәтелә), **аларны бер хәреф – Е хәрефе белән билгелиләр, авазлар калын итеп әйтелә.** Игътибарлы булыгыз! Ике аваз бер хәреф белән билгеләнә».


Фишкалар өстенә **е** хәрефе язылган карточка куела. Аннан соң тәрбияче балалар белән бергәләп авазларны саный һәм беренче ике фишканы алып куеп, алар урынына **е** хәрефе куялар.

# Е е













**3.** *Биек яр* сүзтезмәсенә аваз анализы ясау.

Сүзгә анализ ясап бетергәннән соң, тәрбияче түбәндәге кагыйдәне әйтә: **«Әгәр дә сүздә [й] һәм [э] авазлары бер-бер артлы торсалар** (модельдә аларга туры килгән фишкалар күрсәтелә), **аларны бер хәреф – Е хәрефе белән билгелиләр, авазлар нечкә итеп әйтелә.** Игътибарлы булыгыз! Ике аваз бер хәреф белән билгеләнә».









**4. «Тере модельләр» уены** (*биек яр* сүзтезмәсе белән).
**5.** Балалар **Е, е** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.

## 62 нче шөгыль

| | | | |
|---|---|---|---|
| е | | а | |





| | | | |
|---|---|---|---|
| | а | е | |



| | | | |
|---|---|---|---|
| | и | е | |





| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | а | е | | | а | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | и | е | | | ә | |

**6. Мөстәкыйль эш.**

Бирелгән модельләргә сүзләр табу. Бу мөстәкыйль эшне балаларның белем дәрәҗәсенә карап үткәрергә мөмкин: яхшырак әзерлекле балалар барлык биремнәрне дә үтиләр, калганнары биремне сайлап алып башкаралар.

**Сүзләр белән эш:** *елан, каен, тиен, саескан, киемнәр.*



## 63 нче шөгыль

# Ёё

**Кем ни эшли?**

Контролёр билетлар тикшерә.
Режиссёр спектакль куя.
Актёр театрда уйный.



| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Ё

**1.** Тәрбияче балаларга театр турында сөйли. Балалар түбәндәге сорауларга җавап бирәләр:


– Театрда кем билетлар тикшерә?
– Кем спектакль куя?
– Театрда кем уйный?
– Бу сүзләрдә нинди бертөрле авазлар ишетәсез?


Балаларның игътибары рус теленнән алынган *(контролёр, режиссёр, актёр)* сүзләрдә рәттән торган **[й]**, **[о]** авазларына юнәлтелә.

**2.** *Актёр* сүзенә аваз анализы ясау.

Интонация ярдәмендә сүзнең беренче **[а]** авазын аерып алып әйтегез һәм аңа туры килгән фишканы куегыз. Икенче **[к]** авазын аерып әйтегез һәм зәңгәр фишка белән билгеләгез. Өченче **[т]** авазын аерып, аңа туры килгән яшел фишканы куегыз. Тавышны көчәйтебрәк **[й]** авазын аерып әйтегез, яшел фишка белән билгеләгез. Чираттагы **[о]** авазын көчәйтебрәк әйтегез һәм аны кызыл фишка белән, **[р]** авазын зәңгәр фишка белән билгеләгез.

## 63 нче шөгыль





Сүзгә анализ ясап бетергәннән соң, тәрбияче түбәндәге кагыйдәне әйтә: **«Әгәр дә сүздә [й] һәм [о] авазлары бер-бер артлы торсалар** (модельдә аларга туры килгән фишкалар күрсәтелә), **аларны бер хәреф – Ё хәрефе белән билгелиләр.** Игътибарлы булыгыз! Ике аваз бер хәреф белән билгеләнә. Татар сүзләрендә бу күренеш юк».


**3.** Тәрбияче балаларга **ё** хәрефләрен өләшә. Бергәләп бу хәрефнең хәрефләр кассасындагы урынын билгелиләр. *Контролёр, режиссёр, актёр* сүзләрендә бу хәрефләрнең кайсысы (баш һәм юл) куелуын балалар үзләре аңлатып бирергә тиешләр.

**4.** Балалар **Ё, ё** хәрефләрен (баш һәм юл) язалар.



## 63 нче шөгыль

**е ? ё**



**5.** Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. Театр сурәте төшерелгән рәсемне атаганда, тәрбияче сүзне ишетелгәнчә әйтә һәм балаларга аңлатма бирә: «Исегездә тотыгыз, бу сүз *т[и]атр* дип әйтелә, *театр* дип языла». Балалар калган рәсемнәрдә ук белән күрсәтелгән шакмакларга нинди хәреф язарга кирәклекне билгелиләр – **е** яки **ё** хәрефләре. Аннан соң тиешле хәрефне кызыл карандаш белән язалар.

**6. «Парын тап»** (туп белән уен).

Тәрбияче нинди дә булса калын әйтелешле тартык аваздан башланган сүз әйтеп, тупны балага ыргыта. Бала, шул авазның нечкә әйтелешле парыннан башланган сүз әйтеп, тупны кире кайтара.

**Сүзләр белән эш:** *театр, оекбаш, вертолёт, сыер, самолёт.*

а у ы о

и



а
у
э
я
ю
е

**1. «Укый-яза белүче» уен-биреме.**
Балалар яшел фишкадан соң тиешле хәрефне куялар. Биремне тизрәк үтәп бетергән бала такта янында эшли, бергәләп дөреслеген тикшерәләр.

**2.** *Ил* сүзенә аваз анализы ясау (тартык аваз сары фишка белән билгеләнә, сузык аваз – хәреф белән). **И** хәрефе рәттән **а, у, э, я, ю, е** хәрефләренә алмаштырыла. Балалар яңа сүзләрне «укып» күрсәтәләр.






ә ү э ө и


у
ү
и
э
я



**3. «Укый-яза белүче»** уенының дәвамы.
Балалар зәңгәр фишкадан соң тиешле хәрефне куялар. Биремне тизрәк үтәп бетергән бала такта янында эшли, бергәләп дөреслеген тикшерәләр.

**4.** *Ат* сүзенә аваз анализы ясау. Бу биремне балаларга мөстәкыйль эш итеп бирергә мөмкин. Аннан соң **а** хәрефе рәттән **у, ү, и, э, я** хәрефләренә алыштырыла. Балалар яңа сүзләрне «укып» күрсәтәләр.





а
ү
и
ы
о
ө





**5.** *Кул* сүзенә аваз анализы ясау.

Сузык авазга туры килгән хәрефне бер-бер артлы алыштыра барып, яңа сүзләрне «укып» күрсәтү (балаларга бик үк таныш булмаган сүзләргә тәрбияче тарафыннан аңлатма бирелә).

**6. Мөстәкыйль эш.**

Тәрбияче балаларга Г. Тукайның «Туган тел» шигырен искә төшерергә һәм сөйләп бирергә тәкъдим итә.

Биремнәр:

а) бирелгән схемага туры килә торган сүзләр уйлап әйт (*туган, матур*);

б) *тел* сүзенә аваз анализы ясa;

в) кызыл фишкаларны хәрефкә алыштыр (эш барышында э хәрефенең дөрес язылышы турында кагыйдәне искә төшереп үтәләр);

г) сүзтезмәне модель ярдәмендә «укып», нәрсә язылганын әйтеп бир.





**Туган тел**

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

*Габдулла Тукай*

## Хәрефләр өйрәнәбез

Сезнең алда «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып» ярдәмлегенең икенче эш дәфтәре. Әлеге ярдәмлектә хәрефләрнең парлап бирелүе **(а-ә, у-ү, и, ы-э, о-ө ...)**, беренчедән, яңа белемнәр үзләштерү булса, икенчедән, тартык авазлар турында булган белемнәрен ныгыту да булып тора.

Эш дәфтәрләрендә балалар сүзләргә аваз анализы ясауны дәвам итәләр һәм сузык авазларны белдерүче хәрефләр белән таныша башлыйлар. Сүзнең авазлар моделендә кызыл фишкаларны хәрефләргә алыштыралар. Сүздәге сузык авазларга карап, тартык авазларның калынлыгын-нечкәлеген билгеләргә өйрәнә башлыйлар.

Сузык авазларны язуда белдерә торган хәрефләр белән танышу барышында балалар туган телнең кайбер кагыйдәләре белән дә танышалар. Мәсәлән, сузык аваз хәрефләре ярдәмендә тартык авазларның калынлыгын-нечкәлеген билгеләү принцибы (*кул-күл, тоз-төз, кыр-кер* һ.б.).

Татар теленең балалар белергә тиешле тагын бер бик мөһим үзенчәлеге – *сингармонизм законы*. Бу закон буенча сүз эчендә сузыклар калын яки нечкә генә була ала. Бу үзенчәлек сүзгә кушымчалар ялгаганда да саклана *(кил-ә-ләр, бар-а-лар).*

**Я, ю е, ё** хәрефләре белән таныштыру **[й]** авазы кергән сүзләргә анализ ясаудан башланып китә. Балалар **[й]** авазының тартык аваз булуы һәм аның кыска итеп әйтелүе турында беләләр инде.

Эш дәфтәрләрендә **[й]** авазының **[а]**, **[ә]**, **[у]**, **[ү]**, **[ы]**, **[э]**, **[о]** авазлары белән бер-бер артлы килгән очраклары карала.

Аваз анализы ясаганда, **[й]** авазын аерып алып, аны ишетергә, сүздәге урынын билгеләргә балаларга ярдәм итәргә кирәк. Хәрефләрне белмәгән балалар бу эшне дөресрәк башкаралар. Ә менә укый белгән балалар: «*Ясминә* сүзендә беренче аваз, *кыяр* сүзендә өченче аваз – **[я]** авазы»,– дип әйтәчәкләр. Тәрбиячененң мондый җавапларга әзер булуы һәм балаларга дөрес юнәлеш бирүе бик мөһим. Шулай итеп, балалар **я** хәрефе белән танышалар. Тәрбияче аларны түбәндәге кагыйдә белән таныштыра: «Әгәр дә сүздә **[й]** һәм **[а]**, **[й]** һәм **[ә]** авазлары бер-бер артлы торсалар, аларны **я** хәрефе белән билгелиләр».

Балалар шул рәвешчә **ю, е, ё** хәрефләре белән дә танышалар. Тәрбияче бу хәрефләрнең дә ике аваз җыелмасы булуын аңлата һәм алар турында кагыйдәләр әйтә.

Бу хәрефләр арасыннан **е** хәрефе аеруча игътибарга лаек. Бу хәреф телебездә күптөрле вазифа башкара:

1) сүз уртасында һәм сүз ахырында килгәндә, ул бик кыска әйтелә торган **[э]** авазын белдерә *(бер, кеше).*

2) сүз башында һәм иҗек башында килгәндә, икешәр авазны белдерү өчен кулланыла: **[й], [э]** – *биек,* **[й], [ы]** – *елга, елан.*

3) рус теленнән кергән сүзләрдә киң әйтелә торган русча **[е]** авазын белдерә *(сельдерей).*

Балаларны **э** хәрефе белән таныштырганда, тәрбияче түбәндәге кагыйдә барлыгын әйтә: «Рус теленнән кергән сүзләрдә бу хәреф сүз башында, уртасында, ахырында языла. Ә татар телендә **[э]** авазы сүзнең башында, уртасында, ахырында ишетелсә дә, бу авазны белдергән **э** хәрефе һәрвакыт сүз башында гына языла. **[э]** авазы **э** һәм **е** хәрефләре белән белдерелә».

**Исегездә калдырыгыз! Татар телендә 39 хәреф, 41 аваз (13 сузык аваз, 28 тартык аваз) бар.**

## Эчтәлек


Сәлам, дустым! ....3
43 нче шөгыль ....4
44 нче шөгыль....6
45 нче шөгыль....8
46 нчы шөгыль....10
47 нче шөгыль....13
48 нче шөгыль....15
49 нчы шөгыль....17
50 нче шөгыль....20
51 нче шөгыль....22
52 нче шөгыль....24
53 нче шөгыль....27
54 нче шөгыль....30
55 нче шөгыль....32
56 нчы шөгыль....34
57 нче шөгыль....37
58 нче шөгыль....41
59 нчы шөгыль....44
60 нчы шөгыль....49
61 нче шөгыль....52
62 нче шөгыль....55
63 нче шөгыль....59
64 нче шөгыль....62
Хәрефләр өйрәнәбез ....66

*Учебное издание*

**Шаехова Резеда Камильевна**

**Азбука для дошкольников**
**Играем со звуками и словами**

Рабочая тетрадь № 2
для детей старшего дошкольного возраста

*(на татарском языке)*

Редакторы *Р. Вафина*
Компьютерда биткә салучысы *Э. Уракова*
Корректорлары *Ә. Әхмәдуллина, Н. Габдрахманова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2011.
Форматы 84x108 1/16. Офсет кәгазе.
«Times New Roman» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 4,5. Тиражы 10000 д. Заказ .

Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты.
420111. Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014. Казан, Кремль, а/я 54.
Тел.: (843) 264-67-96.

«Татмедиа» ААҖ филиалы —
«Идел-ПРЕСС» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

## Кушымта

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| А | А | А | а | а | а |
| Ә | Ә | Ә | ә | ә | ә |
| У | У | У | у | у | у |
| Ү | Ү | Ү | ү | ү | ү |
| И | И | И | и | и | и |
| Ы | Ы | Ы | ы | ы | ы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Э | Э | Э | э | э | э |
| О | О | О | о | о | о |
| Ө | Ө | Ө | ө | ө | ө |
| Я | Я | Я | я | я | я |
| Ю | Ю | Ю | ю | ю | ю |
| Е | Е | Е | е | е | е |
| Ё | Ё | Ё | ё | ё | ё |